**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ИСКЕ АБДУЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕК СОВЕТЫ**

# КАРАР

05.12.2018 ел № 8/3

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге карары белән расланган Тукай муниципаль районының «Иске Абдул авыл җирлеге» Советының 2016 елның 28 октябрендәге 15/2 номерлы «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе турындагы нигезләмә»гә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 30 сентябрендәге 286-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 14 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының «Иске Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы,

**Карар бирә:**

1.Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Иске Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 28 октябрендәге 15/2 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе турындагы Нигезләмә»гә түбәндәге узгәрешләр кертергә:

1.1 Нигезләмәнең 4 өлеше түбәндәге редакциядә 4.5. пункт өстәргә:

«4.5. Үзара салым акчаларын җыю тәртибе Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының «Иске Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең норматив хокукый акты белән билгеләнә.»

2.2. Нигезләмәдән 5 өлешне төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Иске Абдул авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында игълан итәргә.

3.Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе Р.Х.Сафина